СОВЕТ НОВОРУССКО-МАМАТКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯҢА РУС МӘМӘТХУҖАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Ул. Центральная, д.5, с. Набережные Моркваши, 422594

Красная ур., 40 нче йорт, Яр Буе Моркваши авылы, 422594

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ КАРАР

28.10.2019 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1 с. Старое Русское Маматкозино 55-271

**Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда аерым нотариаль гамәлләр кылу турында**

«Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге №226-ФЗ Федераль закон нигезендә һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 16.1 статьясына, «Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә үзгәрешләр кертү хакында» (Россия Федерациясе ВС тарафыннан расланган 11.02.1993 N 4462-1) 2008 елның 15 гыйнварыннан җирлекләрнең җирле Администрация Башлыклары (Башкарма комитет җитәкчеләре) һәм нотариус җирлектә булмаган очракта, җирлекләрнең җирле үзидарәләренең махсус вәкаләтле вазыйфаи затлары түбәндәге нотариаль гамәлләр кылырга хокуклы:

1) күчемсез милек белән эш итүгә ышанычнамәләреннән тыш, ышаныч кәгазен расларга;

2) мирас мөлкәте исемлеген җитештерү юлы белән мирас мөлкәтен саклау буенча чаралар күрергә;

3) документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең тугрылыгынраслау;

4) документларда имзаның чынлыгын дәлилләү;

5) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда затлар турында белешмәләрне таныклыйлар;

6) гражданның исән булу фактын таныклыйлар;

7) тиешле җирлек яки муниципаль район территориясендә яшәүче күрү буенча инвалидның үз кулы белән имзасын факсималь күрсәтеп, тәңгәллеген расларга;

8) билгеләнгән урында гражданның урнашу фактын таныклыйлар;

9) фотода сурәтләнгән зат белән гражданинның тәңгәллеген таныклыйлар;

10) документлар тапшыру вакытын таныклыйлар;

11) документның кәгазьдә урнаштырылган тигезлеген раслыйлар;

12) документның кәгазьдә электрон документка тигезлеген таныклыйлар. Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегендә нотариус булмау сәбәпле, «Россия

Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 14.1 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты, 20 статьясындагы 4.1 өлеше, нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренең 1 һәм 37 статьялары нигезендә

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге**
**Карар чыгарды:**

1. Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен 2008 елның 15 гыйнварыннан башкаруда катнашалар дип билгеләргә кирәк.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Башлыгы В.В.Никитушкинны нотариаль гамәлләр кылуга махсус вәкаләтле вазыйфаи зат итеп билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Башкарма комитетына аерым нотариаль гамәлләр башкару вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүче чаралар күрергә.
4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Советының «Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында» 26.02.2008 ел, № 26-132 карары үз көчен югалткан дип санарга

**Совет Рәисе,**
**Татарстан Республикасы**
**Югары Ослан муниципаль районы**
**Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге**
**Башлыгы** **В.В.Никитушкин**